**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.07.2024 Казан № 304

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының аерым бер боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 17 апрелендәге 113 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары реестрын булдыру һәм алып бару Тәртибенә (2021 елның 14 августындагы 240 номерлы боерык белән кертелгән үзгәрешләрне алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта «Ял һәм сәламәтләндерү» сүзләрен «Җәйге ял» сүзләренә алыштырырга;

2.4 пунктның уналтынчы абзацында «кабул иткән очракта» сүзләрен «юллама бирелгән очракта» сүзләренә алыштырырга;

2.6 пунктның икенче абзацында «Н.Столбов ур., 2нче йорт, 410нчы офис» сүзләрен «Сафьян ур., 5нче йорт» сүзләренә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 390 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» сүзләренә алыштырырга;

социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының күрсәтелгән боерык белән расланган билгеләнгән критерийларга туры килүе турында

бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте министрлык тарафыннан гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә күрсәтелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.2 – 2.4.4 пунктлар өстәргә:

«2.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан бердәм порталда (техник мөмкинлеге булганда) яисә республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы һәм бердәм порталның яисә республика порталында шәхси кабинетында чагылдырыла торган «документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән алып 30 көн эчендә Министрлык тарафыннан күрсәтелә (техник мөмкинлекләр булганда).»

2.4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон документлар рәвешендә тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә Министрлык тарафыннан күрсәтелә.

2.4.4. Әлеге Регламентның 2.4.1 – 2.4.3 пунктларында күрсәтелгән сроклар, «коммерцияле булмаган оешмалар - башкаручылар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы дип тану турында Карар кабул итү кагыйдәләренең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан сораулар җибәрелгән очракта, 30 көннән дә арттырмыйча озайтылырга мөмкин».

Күрсәтелгән карарны кабул итү срогының озайтылуы турында Министрлык гариза Министрлыкка кергән көннән алып 30 көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.»;

2.6.2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнарында» сүзләренә алыштырырга.»;

Административ регламентның 1 нче кушымтасында «чит ил агенты функциясен башкаручы» сүзләрен «чит ил йогынтысындагы затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия» сүзләренә алмаштырырга.».

3. Әлеге Боерыкның 1 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Р.Н.Садыйков